| | |
|---|---|
| **СОВЕТ<br>КУЛАНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

“27” апрель 2020 ел Колаңгы станциясе. №6

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Колаңгы авыл җирлеге Советының кайбер
карарларын юкка чыгару турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы һәм муниципаль хокукый актларны муниципаль хезмәт турындагы гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авылы җирлеге Советының:

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авылы җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 7 августының 12 номерлы;

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авылы җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрне бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 21 мартының 3 номерлы;

- «Азык-төлек продуктларын сату һәм аларның әйләнешен гамәлгә ашыруга таләпләр һәм Колаңгы авыл җирлеге территориясендә базар, сәүдә пунктларының эш тәртибе турында» 2007 елның 20 июлендәге 41 номерлы;

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга һәм Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы Ф.Т.Нигматзянов
Кайбыч муниципаль районы
Колаңгы авыл җирлеге Башлыгы